Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 5 ноябре № 9

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 нчы пунктны өстәргә:
«16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү.»;

1.2. 10 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктны өстәргә:
«5.1.) инициативалы проектлар;»

1.3. түбәндәге эчтәлекле 15.1 статьясын өстәргә:
«15.1. статьясы Инициативалы проектлар
1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яки җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлек халкы яки аның өлеше өчен өстенлекле булган чараларны тормышка ашыру максатыннан җирлек Башкарма комитетына инициативалы проект кертелергә мөмкин. Инициативалы проектлар гамәлгә ашырылырга мөмкин булган җирлек территориясенең бер өлешен билгеләү Тәртибе җирлек Советы норматив-хокукый акты белән билгеләнә.
2. Инициативалы проектны кертү инициативасы белән, җирлек территориясендә яшәүче уналты яшькә җиткән һәм уннан да ким булмаган гражданнардан торган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, авыл торак пункты старостасы (алга таба — проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны җирлек Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Проект инициаторы булып чыгыш ясау хокукы, җирлек Советының норматив-хокукый акты нигезендә, шулай ук тиешле җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.
3. Инициативалы проект үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:
1) хәл итү район яки аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган проблеманың тасвирламасы;
2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;
3) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү;

5) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның планлаштырылган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынган затларның планлаштырылган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы турында белешмәләр;

7) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен, планлаштырылган инициатив түләүләр күләменнән тыш, әлеге акчаларны файдалану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтмә;

8) җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә чикләрендә инициативалы проект гамәлгә ашырылырга мөмкин җирлек территориясенә яисә аның өлешенә күрсәтмә;

9) җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициативалы проект, аны җирлек Башкарма комитетына керткәнче, гражданнарның җыенында, җыелышында яки конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яки конференциясендә, инициативалы проект турында фикер алышу, аның җирлек яки аның өлешенең халкы мәнфәгатьләренә туры килүен, инициативалы проектны тормышка ашыруның максатка ярашлыгын билгеләү, шулай ук гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе тарафыннан инициативалы проектка ярдәм итү турында Карар кабул итү максатында карап тикшерелергә тиеш. Шул ук вакытта бер җыенда, бер җыелышта яки гражданнарның бер конференциясендә берничә инициативалы проектны карау мөмкин.

Җирлек Советының норматив хокукый акты белән инициативалы проектка ярдәм итү турындагы мәсьәлә буенча гражданнарның фикерен шулай ук сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Җирлек башкарма комитетына инициативалы проектны керткәндә, проект инициаторлары аңа тиешле рәвештә гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе беркетмәсен, гражданнар арасында сораштыру нәтиҗәләре һәм (яки) җирлек халкы яки аның өлеше тарафыннан инициативалы проектны хуплауны раслый торган имзалар кәгазен теркиләр.

5. Җирлек башкарма комитетына инициативалы проект кертү турындагы мәгълүмат инициативалы проект кертелгәннән соң өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында инициатив проект кертелгәннән соң өч эш көне эчендә бастырылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш һәм әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләр булырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга җирлек Башкарма комитетына инициативалы проект буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеге турында хәбәр ителә, тапшыру вакыты күрсәтелә, ул биш эш көненнән дә ким булмаска тиеш. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яше тулган җирлек халкы җибәрергә хокуклы. Авыл җирлеге башкарма комитетының әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, әлеге мәгълүмат Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге мәгълүмат гражданнарга авыл торак пункты старостасы тарафыннан җиткерелергә мөмкин.

6. Инициативалы проект җирлек Башкарма комитеты тарафыннан аны керткәннән соң 30 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш. Җирлек башкарма комитеты инициативалы проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициативалы проектны хупларга һәм җирле бюджет турындагы карарда каралган тиешле максатларга һәм (яисә) җирле бюджет проектын төзү һәм карау (җирле бюджет турында карарга үзгәрешләр кертү) тәртибе нигезендә бюджет ассигнованиеләре чикләрендә аның өстендә эшне дәвам итәргә;

2) инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тартырга һәм, инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, проектны инициаторларына кире кайтарырга.

7. Җирлек башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициативалы проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициативалы проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, җирлек Уставы таләпләренә туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициативалы проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен, аларны формалаштыру чыганагы инициативалы түләүләр булмаганда, кирәк булган акчалар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициативалы проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

8. Җирлек башкарма комитеты проект инициаторларына инициативалы проектны бергәләп эшләп бетерергә, шулай ук аны компетенцияләре нигезендә башка җирлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы каравына тапшырырга киңәш итәргә хокуклы, ә әлеге статьяның 7 пунктындагы 5 пунктчасында каралган очракта, бурычлы.

9. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

10. Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбенә финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларга карата инициативалы проектларда булырга тиешле мәгълүматлар составына таләпләр, инициативалы проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларга ярдәм итүдән баш тарту нигезләре, мондый инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Россия Федерациясе субъектының законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 пунктларның таләпләре кулланылмый.

11. Әгәр дә җирлек Башкарма комитетына берничә, шул исәптән бертөрле өстенлекле проблемаларны тасвирлаган инициативалы проект кертелгән булса, җирлек Башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проект инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру аны формалаштыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә. Коллегиаль орган (комиссия) составы җирлек Башкарма комитеты тарафыннан формалаштырыла. Шул ук вакытта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санынннан яртысы җирлек Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль органның (комиссиянең) инициативалы проектларны каравында катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проект инициаторлары, җирлек территориясендә яшәүче гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе билгеләгән вәкаләтле башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвештә инициативалы проектны гамәлгә ашыруны иҗтимагый контрольдә тотарга хокуклы.

14. Җирлек Башкарма комитетының инициативалы проектны карау, инициативалы проектны гамәлгә ашыруның барышы, шул исәптән акча средстволарыннан файдалану турында мәгълүмат инициативалы проектны тормышка ашыруның барышы, шул исәптән акча средстволарыннан файдалану, аны тормышка ашыру белән кызыксынган затларның мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Инициативалы проектны тормышка ашыру нәтиҗәләре турында җирлек Башкарма комитеты хисабы инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Авыл җирлеге башкарма комитетының әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, әлеге мәгълүмат Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге мәгълүмат гражданнарга авыл торак пункты старостасы тарафыннан җиткерелергә мөмкин.

1.4. 16 статьяда:

а) 16 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктчаны өстәргә:

«7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктын өстәргә:

«10.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициативалы проектны проект инициаторлары сыйфатында тәкъдим итә алалар.».

1.5. 20 статьяда:

а) 1 пунктта «җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи затларын да» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу,» сүзләрен өстәргә

б) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»

1.6. 23 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә: «Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яки аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»

б) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 нче пунктчаны өстәргә:

«3) уналты яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яки аның өлешендә яшәүчеләрне – әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

в) 5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар арасында сораштыру үткәрүне билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге җирлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Җирлек Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында карарында түбәндәгеләр билгеләнә:»

г) 5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пунктчаны өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе»;

д) 7 пунктның 1 пунктчасына «яисә җирлек халкын» сүзләрен өстәргә;

1.7. 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:

«2.1.Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган рәвештә гамәлгә ашыру өчен эш урынын (вазыйфасын) айга өч эш көне тәшкил иткән чорга саклап калу гарантияләнә.»;

1.8. 49 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« - полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирә.».

1.9. түбәндәге эчтәлекле XI.1 бүлеген өстәргә:

XI.I. бүлеге МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮ

71.1 статьясы Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт-гражданнарның хезмәт килешүе (контракт) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган һөнәри эшчәнлеге.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәтне финанслау Җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

4. Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнарның муниципаль хезмәткә тигез хокуклы һәм аның җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә, инануларына, җәмәгать берләшмәләренә карауларына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга бәйсез рәвештә муниципаль хезмәткә керү һәм аны үтәү мөмкинлеге бертигез.

Һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәк булган белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе белән шулай ук белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралырга мөмкин.

5. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләү, муниципаль хезмәт үтү шартлары һәм тәртибен дә кертеп, Федераль закон, шулай ук аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары, әлеге устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

71.2 статьясы Муниципаль хезмәт вазыйфасы

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – әлеге Устав белән, җирле үзидарә органы, Сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча вазыйфаларның билгеләнгән даирәсе нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органында, Сайлау комиссиясе Аппаратындгы вазыйфа.

71.3 статьясы Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар — җирлек Советы депутаты, җирлек Башлыгы, даими нигездә эшләүче һәм хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия, комиссиядә даими (штат) нигезендә эшләүче юридик зат булган җирлекнең сайлау комиссиясе әгъзасы

2. Муниципаль хезмәткәр – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча җирлекнең җирле бюджеты акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата хезмәт хакы өчен вазыйфа башкаручы граждан.

3. Җирле үзидарә органнары, сҗирлекнең Сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү буенча вазыйфаларны башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмиләр һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

71.5 статьясы Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр

1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләнә:

1) вазыйфаи бурычларын вазыйфаи инструкция нигезендә үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) акчалата хезмәт хакын үз вакытында һәм тулы күләмдә алу хокукы;

3) Эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән, ял көннәре һәм эшләми торган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләнә торган отпуск белән тәэмин ителә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыккач та, медицина хезмәте күрсәтү;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлык белән бәйле рәвештә пенсия белән тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең үлеме үз вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә барлыкка килгән очракта, аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү;

6) аларның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерү очрагына мәҗбүри дәүләт иминияте;

7) муниципаль хезмәт узган чорда яисә ул туктатылганнан соң, әмма аларның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә килеп туган авыру яисә эшкә яраклылык югалу очрагына мәҗбүри дәүләт социаль иминияте;

8) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда аларның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле көч куллanудан, янаулардан һәм башка хокуксыз гамәлләрдән яклау.

2. Җирле үзидарә органы, Җирлекнең Сайлау комиссиясе юкка чыгуга йә җирле үзидарә органы, Җирлекнең Сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләренең штаты кыскаруга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешманы бетерүгә яки оешма хезмәткәрләренең штаты кыскаруга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта хезмәт законнары белән билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, муниципаль хезмәттән киткәндә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү түләнә. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне түләү шартлары, күләме һәм тәртибе, җирлек Советы тарафыннан расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне түләү тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.»

1.10. 79 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.11. түбәндәге эчтәлекле 81.1 статьясын өстәргә:

«81.1 статьясы Инициативалы проектларны тормышка ашыруны финанс һәм башка яктан тәэмин итү

1. Әлеге уставның 15.1 статьясында каралган инициативалы проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып җирлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан инициативалы түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып төзелә торган җирлек бюджеты турындагы карарда инициативалы проектларны гамәлгә ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициативалы түләүләр дигәндә ирекле нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында җирле бюджетка күчерелә торган гражданнарның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затларның акчалары аңлашыла.

3. Әгәр дә инициативалы проект гамәлгә ашырылмаган булса, инициативалы түләүләр җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча инициативалы проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициативалы түләүләр калдыгы барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән түләүләр җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш.

Аларны җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициативалы түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициативалы проектларны тормышка ашыру, шулай ук, кызыксынган затларның ирекле милек һәм (яки) хезмәт катнашуы рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин.»

2. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 79 статьяның 3 пунктының, 84 статьяның 5 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http:// kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Ф.Х.Гарифуллина